Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Суровка авылы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«23» ноябрь, 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Суровка авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2022 елда яшәү урыны буенча Новотроицк авыл җирлеге Суровка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру;
2) Юлларны ремонтлау (вак таш, ком, асфальт валчыгы сатып алу);
3) Электроматериаллар сатып алу, урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру;
4) Суровка авылында ясалма юл тигезсезлекләрен урнаштыру буенча эшләр башкару;
5) Суровка авылында юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру;
6) Суровка авылында урам күрсәткечләрен сатып алу һәм урнаштыру».

2. Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Суровка авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Суровка авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Новотроицк авыл җирлеге Башлыгы Ю.М. Рыбакова